ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/11

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» № 178-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге 43/9, 2010 елның 26 маендагы 50/8, 2011 елның 15 декабрендәге 15/9, 2012 елның 20 апрелендәге 18/8, 2015 елның 15 апрелендәге 39/11, 2018 елның 21 февралендәге 23/10 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 5 пунктның 11 пунктчасында «урта (тулы) гомуми белем» сүзләрен «урта гомуми белем» сүзләренә алыштырырга;

2) 10 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

3) 12 пунктның 8 пунктчасында «ябык» сүзен «гавами булмаган» сүзләренә алыштырырга;

4) 32 пунктта «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

5) 39.1 пунктының 1 абзацында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

6) 39.2 пунктының 1 абзацында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

7) 47.1 пунктында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

8) 82 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«82. Муниципаль милек реестры Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алып барыла».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев